| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.12.2020 Казан шәһәре № 704/2020

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында

б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 4 августындагы 290/2020 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:<br>а) җайга салынулы оешма тарифларының кулланучылар өчен куллана алырлык булмавы | Кагыйдәләрнең 29 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| нигезләренең тулы исемлеге | (тарифларны куллана алырлык булмау сәбәпле баш тарту концессионер тарафыннан концессия килешүе нигезендә үзәкләштерелгән җылылык белән тәэмин итү системасы объектларын төзү, үзгәртеп кору һәм модернизацияләү буенча йөкләмәләрен үти алмау ихтималын китереп чыгара торган очраклардан тыш);<br>б) төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый тәэмин итү функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимиятн органы тарафыннан расланган җитештерү булмаган объектлар һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары өчен эреләндерелгән смета нормативлары буенча билгеләнгән чараларның инвестиция программасында каралган чараларны гамәлгә ашыру чыгымнарын арттырып җибәрүе;<br>в) раслана торган инвестиция программасына концессия килешүе нигезендә кертелгән чараларны гамәлгә ашыру һәм җайга салынулы оешманың концессия килешүе үз көченә кергәннән соң расланган һәм концессия килешүенә кертелгән чараларны, тоташтырган (техник ялгаган) өчен түләү хисабына финанслана торган чаралардан тыш, үз эченә алган инвестиция программасына концессия килешүе нигезендә кертелгән чараларны гамәлгә ашыру чыгымнары суммасының, концессия килешүе объектын булдыру һәм (яки) үзгәртеп кору һәм (яки) модернизацияләү, әхлакый тузган һәм физик таушалган, концедент тарафыннан концессия килешүе буенча концессионерга тапшырыла торган башка мөлкәтне тагын да җитештерелешлерәк, мондый мөлкәтнең характеристикалары һәм файдалану үзлекләре башкача яхшырак булган яңа мөлкәткә алмаштыру (концессия килешүе нигезендә концессионер гамәлгә ашырырга планлаштырган) чыгымнарының чик суммасының артып китүе | »; |

2.14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый | Дәүләт хезмәте түбәндәгеләр белән җиһазландырылган биналарда күрсәтелә:<br>һаваны кондиционерлау системасы белән;<br>янгынга каршы система белән һәм янгын сүндерү системасы белән;<br>документларны рәсмиләштерү өчен мебель белән;<br>мәгълүмат стенды белән.<br>Инвалидларга һәм хәрәкәт итү мөмкинлекләре чикләнгән затларга дәүләт хезмәтләрен күрсәтү яшәү урыны буенча яисә видеоэлемтә аша, интернет аша дистанцион режимда гамәлгә ашырылырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, | «Россия Федерация-сендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | текстлы мәгълүмат Дәүләт комитетына төп керү юлы янында һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләре бүлеге аша керү урынында, Мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның да чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, мәгълүмат такталарында урнаштырыла.<br>Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, объектлардан һәм хезмәт күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:<br>объектларга һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән тоткарлыксыз файдалана алу шартлары;<br>Дәүләт комитеты территориясе буйлап мөстәкыйль хәрәкәт итә алу, объектларга керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;<br>күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга объектларда ярдәм күрсәтү;<br>инвалидларның объектлардан һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;<br>хезмәттән файдалану өчен кирәкле, тавыш ярдәмендә һәм күрсәтмә мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм Брайль рельеф-нокта шрифтлары белән һәм контраст фонында башкарылган текстлы һәм графиклы башка мәгълүматны кабатлап күрсәтү, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене, шулай ук ишарә телен белә торган башка затны кертү;<br>Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка сукырларны озата йөри торган этне кертү;<br>хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга алар өчен үтемле формада хезмәт күрсәтү тәртибен аңлатуга, аны күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерүгә, инвалидларны кабинетларның урнаштырылу тәртибе белән таныштуыруга, хезмәттән файдалану өчен кирәкле гамәлләр эзлеклелегенә бәйле кирәкле ярдәмне күрсәтү;<br>инвалидларның яшәешендәге чикләүләрне | |

| | | |
|---|---|---|
| | исәпкә алып, электрон рәвештә дәүләт хезмәтләреннән файдалана алу мөмкинлеге;<br>хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәттән файдалануга комачау итә торган каршылыкларны үтүдә кирәкле башка ярдәм күрсәтү.<br>2016 елның 1 июленнән соң капиталь ремонт, реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр | »; |

3.5.3 пунктта «Кагыйдәләрнең 30 пункты» сүзләрен «әлеге Регламентның 2.8 пунктында» сүзләренә алмаштырырга;

3.5.8 пунктның өченче абзацында «Кагыйдәләрнең 30 пункты» сүзләрен «әлеге Регламентның 2.8 пунктында» сүзләренә алмаштырырга;

2. Бу карар аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Л.В.Хәбибуллинага йөкләргә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром